**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**18.11.2023 г.** **№ 20**

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 29 ноябре 16.00 сәг. Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Җыенны уздыру урыны итеп Ижевка авылы, Совет урамы 26 йорт адресы буенча урнашкан Ижевка авыл мәдәният йортын билгеләргә

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

« «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, югары һәм урта уку йортларында көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 -2 төркем инвалидлардан, 80 яшь һәм өлкәнрәкләрдән, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләрен түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:

1. Урам яктырткычларын сатып алу һәм ремонтлау 5 данә

2. Һәйкәлнең һәм скверның административ бина янындагы территориясен төзекләндерү.

3. Ижевка авылына керү урынында стела сатып алу һәм урнаштыру

4. Ижевка авылы буенча үлән чабу һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу

5. Триммер сатып алу - 2 данә

6. Яшьләр тыкрыгы буенча вак таш сатып алу, китерү , тигезләү

7. Трактор өчен трейлер сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Ижевка авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

8. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә

Ижевка авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы Р.Т.Масагутова